Personalia

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-24-1-118-128

# THE IMAGE OF KAYUM NASYRI IN THE WORLD OF TATAR THEATRE AND CINEMA

**Gulnara Fandasovna Zamaletdinova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Gulusya Aksoy,**
Bartin University,
Turkey, 74110, Bartin City, Kutlubey/Center,
gaksoy@bartin.edu.tr.



**Nasyrov Gabdelkayum Gabdennasyrovich (Kayum Nasyri)** (2 [14] February 1825 – 20 August 1902) was an outstanding scientist, writer and educator of the 19th century, the author of more than

**Насыйров Габделкаюм Габденнасыйр улы (Каюм Насыйри)** (1825 елның 2 [14] феврале – 1902 елның 20 августы) – XIX гасырның күренекле галиме, язучысы һәм мәгърифәтчесе, фи-

**Насыров Габделькаюм Габденнасырович (Каюм Насыри)** (2 [14] февраля 1825 – 20 августа 1902) – выдающийся ученый, писатель и просветитель XIX века, автор более 60 научных и перевод-

60 scientific and translated works on philology, folklore, pedagogy, fiction, mathematics, history, geography, astronomy, etc., the creator of the first textbooks in the Tatar language on various branches of science. He was a graduate of the madrasah at the Fifth Cathedral Mosque (1841–1855), a teacher of the Tatar language at the Kazan Theological School (Kazan Theological Seminary, 1855–1871), the founder and teacher of the Russian-Tatar school for boys in Kazan (1871-1876), a full member of the Society of Archeology, History and Ethnography at Kazan University (1885–1902). The central street of Kazan, located in the historical district of Staro-Tatarskaya Sloboda, is named after K. Nasyri. In 1995, the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan established the K. Nasyri Prize, which is awarded in the field of education and the implementation of the pedagogical heritage of the scientist-educator. In 2014, the Scientific and Educational Center "Kayum Nasyri Institute" was established on the basis of Kazan Federal University. In 2025, the Bank of Russia issued a commemorative silver coin dedicated to K. Nasyri.

B. M. Almenov. "Kayum Nasyri". Portrait. Paper, autolithography. 1950.

лология, фольклор, педагогика, матур әдәбият, математика, тарих, география, астрономия һ.б. буенча 60 тан артык фәнни һәм тәрҗемә хезмәтләре авторы, татар телендә төрле фәннәр буенча беренче дәреслекләр төзүче, бишенче Җәмигъ мәчете каршындагы мәдрәсәне тәмамлаган (1841–1855), Казан дини училищесында татар теле укытучысы (Казан дини семинариясе, 1855–1871); Казанда малайлар өчен рус-татар мәктәбенә нигез салучы һәм укытучы (1871–1876), Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1885–1902). Казанның Иске Татар бистәсе тарихи районында урнашкан үзәк урамы К.Насыйри исемен йөртә. 1995 елдан башлап ТР Министрлар кабинеты карары нигезендә мәгариф оешмаларына һәм укытучыларга К.Насыйри премиясе бирелә. 2014 елда Казан федераль университеты базасында «Каюм Насыйри институты» фәнни-мәгариф үзәге төзелде. 2025 елда Россия Банкы К.Насыйрига багышланган истәлекле көмеш тәңкә чыгарды.

Б. М. Әлминов «Каюм Насыйри» портреты. Кәгазь, автолитография. 1950.

ческих работ по филологии, фольклору, педагогике, художественной литературе, математике, истории, географии, астрономии и др., создатель первых учебников на татарском языке по разным отраслям науки, выпускник медресе при пятой соборной мечети (1841–1855), преподаватель татарского языка Казанского духовного училища (Казанская духовная семинария, 1855–1871); основатель и преподаватель русско-татарской школы для мальчиков в Казани (1871–1876), действительный член Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете (1885–1902). Именем К. Насыри названа центральная улица Казани, расположенная в историческом районе Старо-Татарская слобода. В 1995 году Кабинет министров РТ учредил премию имени К. Насыри, которая вручается в области просвещения и внедрения педагогического наследия ученого-просветителя. В 2014 году на базе Казанского федерального университета образован Научно-образовательный центр «Институт Каюма Насыри». В 2025 году Банком России выпущена памятная серебряная монета, посвященная К. Насыри.

Б. М. Альменов Портрет «Каюм Насыри». Бумага, автолитография. 1950.

**For citation:** Zamaletdinova, G., Aksoy, G. The image of Kayum Nasyri in the world of Tatar theatre and cinema // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 118–128. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-118-128

**Сылтама өчен:** Җамалетдинова Г.Ф., Аксой Г.Г. Татар театры һәм киносы дөньясында Каюм Насыйри образы // Tatarica. 2025. № 1 (24). 118–128 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-118-128

**Для цитирования**: Замалетдинова Г.Ф., Аксой Г.Г. Образ Каюма Насыри в мире татарского театра и кино // Tatarica. 2025. № 1 (24). С. 118–128. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-118-128

February 14, 2025 marks the 200th anniversary of the outstanding Tatar scholar, educator and writer Kayum Nasyri. "During more than forty years of his creative work, the indefatigable educator published over sixty original and translated works and textbooks, including the ones on natural science ("Bush vakyt" – "At Leisure", 1860), botany and folk medicine ("Golzar va chamanzar" – "Flowers and Herbs", 1894), anatomy and hygiene ("Manafigel-agza va kanune sikhat" – "The Functions of Body Organs and Hygiene Rules", 1894), physics and metalworking technology ("Sanaigi golfaniya" – "Galvanization", 1900), mathematics ("Khisaplyk" – "Arithmetic", 1873; "Gyilme han-

dasa" – "Geometry", 1895), agriculture ("Gyilame ziragat" – "Agriculture", 1892), cooking ("Irshadel-atbikha" – "Guide to Cooking", 1893), pedagogy ("Gakaid risalask" – " A Book of Faith", 1867; "Kabusname", 1881; "Akhlak risalase sagyr" – "An Abridged Book on Ethics", 1884; "Utyz vagaz" – "Thirty Precepts", "Akhlak risalase kabir" – "A Big Book on Ethics", 1890; "Tarbia kitaba" – "A Book on Education", 1891), history ("Zobdate min tavarikhe rus" – "The Most Important Stages of Russian History", 1890), geography ("Istyylyakhate zhegrafiya" – "Terminology of Geography", 1890; "Zhegrafiyai Kabir" – "Great Geography" in three parts, 1898–1899), ethnography ("Beliefs and Rituals of Kazan Tatars", 1880), as well as numerous articles on various branches of knowledge, which were placed in twenty-four annual calendars and left a deep mark on the history of Tatar culture and public thought" [1].

Ten years ago, the journal "Tatarica" published an article, which gave a detailed analysis of Kayum Nasyri's nine scientific linguistic works [2], whereas the purpose of the present article is to reveal the unique ways of interpreting the image of the enlightener on the stage of the Tatar theatre and in the cinema.

As Tatar society develops, the perception of Kayum Nasyri and his social role has changed. When the scholar was alive, his compatriots gave him unflattering nicknames *Urys Kayum* (Russian Kayum) and *Satlyk* (Traitor) for teaching at the Kazan Theological College and Seminary (1855–1871), for opening a Russian-Tatar elementary school (1871–1876), for his knowing Russian, advocating its study and communicating closely with Russian scientists.

As the enlightener was blind in one eye, this physical impairment served as a basis for another nickname – *Kyly / Sukyr Kayum* (Blind Kayum).

In his historical dilogy "The Turmoil. The Muhajirs" (1930, 1934) [3], M. Galyau brilliantly reflected the contradictions in the perception of Kayum Nasyri's personality in Tatar society. On the one hand, some Tatars saw the blind Kayum, who lived in the house of the merchant Aitov, as an educated man, an expert in the Russian world, to whom they could always turn for advice, as he enjoyed the respect of Russians: "After that, it would be a good idea to talk to the blind Kayum*. He is said to communicate with the Urus-ulaks (Russians). He might be living in Ait Bai's house... If you ask, they will show you the way. And then, if you want, you can come to a Russian himself." ("Аннан соң Сукыр Каюм* белән дә сүйләшеп узу зыян итмәс. Аны да урыс-улак белән аралаша дип сүйлиләр. Аит бай йортында тора бугай... Сорашырсың – күрсәтерләр. Ә инде соңыннан, кирәге булса, урысның үзенә дә барып килерсең") [3].

On the other hand, the conservative strata of Tatar society showered him with curses for his friendship with Russians, for creating scientific works that served as the foundation for Jadidism, this was the sin for which K. Nasyri was going to go to hell: "As in other times, all the questions revolved around the same third group. The result of all the disputes was to ridicule this group, which was called "Jadids", and "send it to the bottom of hell". Once, the recently deceased Marjani, Blind Kayum, Faizkhanov and Gasprinsky, the newly famous Galimjan Mullah Barudi, who was just beginning to gain fame, and young people who were starting to write literary books in the Tatar vernacular, those who having raised many new issues for the Tatar world and having left behind a wealth of scientific works, were lined up and "thrown to hell" ("Бүтән вакытлардагы шикелле бу юлы да бүтен мәсьәләләр баягы үченче түркемне сүгүгә кайтып кала иде. Бүтен талашларның йомгагы 'җәдитчеләр' дип йүртелә торган шушы түркемне мыскыллап, 'җәһәннәм түбенә олактыруга' кайтып калды. Беруңайдан, татар дүньясы үчен күп кенә яңа мәсьәләләр күтәреп, үзеннән соң байтак гыйльми әсәрләр калдырып күптән түгел генә үлгән Мәрҗанине, Сукыр Каюмны, Фәезханов белән Гаспринскийны, яңа гына атагы чыга башлаган Галимҗан мулла Барудины, урам телендә татарча әдәби китаплар язып чыгара башлаган яшьләрне – барысын бер җепкә тезеп 'җәһәннәмгә аттылар'") [3].

In 1945, on the eve of the 120th anniversary of the outstanding Tatar scholar and educator, the writer M. Gali brought the first version of his work about Kayum Nasyri to the Galiasgar Kamal Tatar State Academic Theatre. The director, Kh. Urazikov, took the responsibility to finalise the "half-baked" work, helped the author overcome the vagueness of the plot, united all the events around the central one – the arrival of Mufti S.-G. Tevkilev, who was the religious leader of the Muslims of inner Russia, at Kazan. In accordance with the canons of socialist realism, both the dilogy by M. Galyau and the play "Kayum Nasyri" preserved the antithesis in the depiction of two camps: progressive thinkers and reactionaries, common people and the tsarist government.

As the theatre expert G. Arslanov noted, the director strove to make the plays true to life. The artist, M. Sutyushev, prepared sketches of the interior and the costumes, having studied the interiors of Tatar rich landowners' (bais') houses in Novaya Sloboda and photographs from newspapers and books. The musical overture by J. Fayzi not only conveyed the spirit of K. Nasyri's era, but also revealed his "rich spiritual world".

The main character appeared on stage not in a spectacular, but in a rather simple and casual manner. The director decided to show him with books in his hands to emphasize the character's high level of learnedness. The audience first saw the character carrying books to the shop accompanied by an unknown student. Nasyri was shown as an ordinary Tatar old man wearing a hat, a knee-length coat, light boots and rubber overshoes.

In Kh. Urazikov's interpretation, K. Nasyiri was "a common man, a mere mortal". The director also "lowered the external characteristics of the image, emphasizing his physical impairment." The actors contributed to the development of K. Nasyiri's image on stage. The actor F. Khalitov showed the educator as "a short, slightly round-shouldered, thin old man," withdrawn and reserved. The actor N. Gainullin, who was no stranger to declamatory speeches, created a more emotionally vivid image –a hero who exposes social vices.

"In the second act, the director described Nasyri's dwelling in great detail": it was a small room in the semi-basement. The furniture included a sake (a wooden part of the floor raised by 40–50 cm), his desk, and a low desk for his adopted son's studies. The scholar's room was littered with books and manuscripts, a globe adorned the windowsill and a guitar hung on the wall. A carpenter's workbench and tools could be seen through the open door to the next room. According to the director's plan, "the world of things" was supposed to create the image of the scholar's multifaceted personality. In the third act, the scholar communicated freely with his relatives (his older brother Gabdulkhay) and Gali Chokry. In the fourth act, the high and mighties chastised the protagonist for his "shameful behaviour": the scholar did not show up to bow to the mufti. The culminating scene of the play was the protagonist's meeting with his ideological opponents. The director deliberately deprived these characters of individuality through standardizing their costumes and gestures. Just like in M. Galyau's novel, in this play, the reactionaries cursed the educator, promising to tear him to pieces at a personal meeting. The meeting with Tevkelev was structured as a clash between a small man and an important person. In the mise-en-scène, a frail, strong-willed old man was contrasted to the mufti who took off his clothes of a religious minister in order to indicate to those around him through the uniform of a tsarist general that he personified power. Within the framework of the established tradition, the director used this stage metaphor to point out the unity of tsarist power and religion. K. Nasyri confronted the general and his retinue alone. Words of repentance were expected of him, but the protagonist quoted an Arab poet and left the rich man's house. In revenge, the scholar was evicted from his room and summoned to the police station. Yet, his final monologue sounded like a prophecy, heralding the onset of a happy time in the life of the nation under the banner of the enlightenment. (See the detailed analysis of the performance in the article by M. Arslanov [4]).

Thanks to the translation into Russian, K. Nasyri's fairy tale story "Abugalisina" [5] began to gain popularity among readers. Using the example of Avicenna, the author "sought to show the superiority of the mind and moral qualities over wealth and nobility." The Tatar educator found "his positive ideal in a real historical person" [6, p. 187].

A. Akhunov considered the year 1975 to be an important milestone in the "rehabilitation" and "canonization of the Tatar educator's legacy": "The interest in his personality and works increased sharply. Nasyri began to be actively studied, his works were published both in academic journals and in an adapted form for children in hundreds of thousands of copies. Together with such outstanding personalities as Tukay and Jalil, Nasyri's name became known not only in the Soviet Union, but also beyond its borders. He became one of the key figures of Tatar culture, a symbol of its intellectual and spiritual legacy, its brand, his ideas acquired relevance and significance again, albeit in a somewhat adapted and censored form" [7].

The Tatar audience warmly received the television film based on Ravil Bukharaev's play "Kayum Nasyri Street" (1989), in which Ildus Fayzov created the film character of the famous thinker.

In 1990, another book by the scholar, "A Book on Education" [8], was especially popular among the general readership and was widely quoted.

In 2019, the first Tatarstan blockbuster "Vodyanaya" ("The Water Witch") was filmed, based on Tatar folk myths analyzed by K. Nasyri. The director of this family adventure film in the genre of fantasy was Alexey Barykin. The film received mixed reviews from the public. Tatar folklore fans simply did not "recognize" it in the film. A. Barykin tried to combine folklore motifs with modern technologies. In "Vodyanaya" ("The Water Witch"), Muslim culture is combined with paganism owing to the high level of mysticism embedded in this film. Within the "children's theme", the film raises serious issues concerning family relationships, lack of love and communication. The cameramen strove to show the life of a provincial family in detail. The film was criticized for the schematic storyline, poorly developed dialogues, and the lack of balance between a children's adventure and a "horror". The acting, make-up and costumes also gave rise to many unfavourable comments. Nevertheless, everyone liked the acting of Nafisa Khairullina who played the greedy villainess, manipulating the children's actions (see, for example, the reviews by A. Zagrutdinov [9] and T. Mamaeva [10]).

The name of K. Nasyiri is mentioned in the film several times. Firstly, as a folklore collector of Tatar myths. Secondly, in an implicit way, through the display of a meadow with wooden figures of mythological heroes (Kamil Khazret works on the statue of Yukha, an evil spirit of water). A part of the film unfolds in the interiors of the museum located in the village of Bolshiye Achasary where the authentic things belonging to Kayum Nasyri are kept.

On the eve of his 200$^{th}$ anniversary, the fairy tale story about Abugalisina was transformed into a stage performance by Aigul Akhmetgalieva. The play "Abugalisina", based on the fairy tale by Kayum Nasyri (directed by Gulnaz Minkina), premiered on March 25, 2022. The story turned into a parable in two acts, and the key events were transferred to Egypt. On January 18, 2023, the director Aigul Fayzrakhmanova staged the musical "Abugalisina", based on the dramatization by A. Akhmetgalieva with young artists from the drama studio "Apush" in the Chulpan Cultural Centre (see more details in the article by M. M. Khabutdina [11]).

In 2025, the premiere of the documentary film "Connecting Worlds" (directed by Andrey Lysyakov) took place. The film was shot at the request of the Kultura Channel, it aimed at creating a portrait of the Tatar scholar and educator who, thanks to his self-sacrificing activities, managed to connect the world of Russian and Tatar Kazan, in every possible way contributed to reducing the distance between the educated and uneducated parts of his compatriots, visually demonstrated the practical application of scientific knowledge, etc. The film features K. Nasyiri in his youth as a shakird (a madrasah student) (D. Zinnatullin) and in maturity as a scholar and educator (F. Zhikhansha). The versatility of the protagonist's personality is revealed through the author's interviews with scientists, museum employees, journalists and representatives of the clergy. The chronotope of the path plays an important role in the film: a village path turns into a wide avenue of knowledge connecting two parts of Kazan, separated by the Bulak Canal. The film focuses on the literacy level of the Tatar population in the region, as well as the role of mullahs, acting as intermediaries between the tsarist government and the Tatars. The process of mastering the Russian language by the clergy and the educated part of the Tatars is shown in dynamics. The life of the region is depicted against the background of historical changes and challenges of the era. The film features the role of the specific person from the common people in the radical restructuring of society in accordance with the enlightenment beliefs of the era. The author of the film constantly focuses on the desire of the scholar to remove contradictions and establish a dialogue between the Muslim and Orthodox worlds, reactionaries and reformers, so that the region could become prosperous. In its aesthetics, the film resembles an advertising video for tourists, as it abounds in views of modern Kazan and natural attractions of its countryside. The atmosphere of learnedness is established through the halls of the university library and museum interiors. It is also supported with other signs of learnedness such as books, manuscripts, a magnifying glass, a pen with ink, a pencil and a dombra. The young shakird, jumping over the path, becomes increasingly symbolic as the plot develops: having become a learned man, K. Nasyiri builds a spiritual bridge between the worlds. Different facets of the educator's personality are revealed by representatives of different strata of modern Tatars. Thanks to documentary sources, the film dispels the myths that the scholar is a poor and untidy hermit. Unfortunately, the main character himself remains "mute", as the film neither cites his works, not specifies his achievements. The lion's share of the film is dedicated to the way the Russian language

opens the door to the big world of knowledge for him [10].

Enzhe Dusayeva and Dina Khabibullina created a promenade performance "Kayum Nasyri: The Coat with Fur Outside" (the script by M. Gafurova). The route of the walk runs through the following locations in the city of Kazan: Sennoy Bazar, Kirov Garden, Karl Fuchs House, a bookstore, the Galiev Mosque and the Kayum Nasyiri Museum. The performance is aimed at showing how his memory has been preserved. During the excursion, the group meets Gulhabiri Nasyria (Dina Khabibullina), Kayum Nasyri's (Ilgizar Khasanov) niece who inspired him to create the "Persian-Arabic-Turkic (Tatar) Dictionary". She talks about her uncle's scientific work. Then, the spectators overhear a conversation between two shakirds who condemn K. Nasyri for teaching at a seminary. In the bookstore, the scholar himself tells how he began to publish calendars. The tour ends in his memorial house-museum where visitors are introduced to the learned man's lifestyle. At the end, K. Nasyri's will is read, which destroys the myths about his poverty and atheism.

To celebrate the 200th anniversary of the ethnographer, the Central Bank of the Russian Federation issued a commemorative silver coin worth 2 roubles.

The works of K. Nasyri have not lost their relevance to this day.

In November, the Kayum Nasyri Institute under the guidance of the Institute of Philology and Intercultural Communication (KFU) was opened in Minsk on the basis of the Belarusian State Technological University, and became its 15th branch. Similar centres function in other foreign cities such as Astana, Baku, Bishkek, Tashkent, and in 10 regions of Russia.

A new feature film, based on K. Nasyri's fairy tale "Baidek", is expected to be released in the near future. In 2024, the Ministry of Culture of the Republic of Tatarstan allocated a subsidy of 2 million roubles to the director F. Makhmudov ("Mahabbat" Studio). The working title of the film, which glorifies family values, is "The Adventures of Baidek".

Indeed, cinema and television play an important role in promoting K. Nasyri's legacy, in turning the scholar into a recognizable media figure. It is gratifying to know that the Tatar writer is becoming the main character in films of different genres. The creators, in accordance with the aesthetics of a particular genre, strive for biographical authenticity, showing the enlightener as a living person with his dreams and passions.

**References**

1. *Kayum Nasyiri* (2008) [Kayum Nasyri]. Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkologicheskaya lingvisticheskaya shkola. Sost. M. Z. Zakiev. Pp. 32–36. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

2. Galiullina, G. R., Yusupova, A. Sh. (2015). *Kayum Nasyiri khezmətlərendə tatar beleme nigezləre (galimneң tuuyna 190 el tulu uңaennan)* [Foundations of Tatar Linguistics in the Works of Kayum Nasyri (on the 190th anniversary of the scholar's birth)]. Tatarica. No. 4, pp. 7–17. (In Tatar)

3. Galyau, M. *Məhaҗirlər* [Migrants]. Kazan, Tatar. kit. nəshr. URL: kitaphane.tatarstan.ru›eng/file/pub/pub_26769.doc 6lr%3D43%26mime%3Drtf%26l10n%3Dru%26sign%3De07235d8566f37fb9f984de60d796c72%26keyno%3D0%26nosw%3D1 (accessed: 14.02.2025). (In Tatar)

4. Arslanov, M. (2013). *Spektakl' "Kayum Nasyiri" na stsene Tatarskogo akademicheskogo teatra im. G. Kamala* [The Play "Kayum Nasyri" on the Stage of the G. Kamal Tatar Academic Theater]. Gasyrlar avazy. Ehkho vekov. No. 3–4, pp. 248–255. (In Russian)

5. Nasyiri, K. (1957). *Abugalisina* [Abugalisina]. Per. s tat. B. Ibragimov; obrabotka G. Lutfi. 60 p. Kazan', Tatknigoizdat. Red. yunosh. det. lit. (In Russian)

6. Gainullin, M. (1975). *Tatarskaya literatura XIX v.* [Tatar Literature in the 19th Century]. 307 p. Kazan', Tat. kn. izd-vo. (In Russian)

7. Akhunov, A. (2025). *Yubilei dlya galochki: Tatarstan ne zametil 200-letie velikogo prosvetitelya* [The Anniversary for Show: Tatarstan Did Not Notice the 200th Anniversary of the Great Educator]. Biznes-Onlain. 16 fevralya 2025 g. URL: https://www.business-gazeta.ru/article/663317. (In Russian)

8. Nasyiri, K. (1992). *Kitab-eht-tehrbiya. Kniga o vospitanii* [A Book on Education]. Kazan', Tatarskoe knizhnoe izdatel'stvo. (In Tatar)

9. Khabutdinova, M. M. (2023). *Obraz Abugalisiny v tatarskoi literature* [The Image of Abugalisina in Tatar Literature]. M. M. Khabutdinova. Russian Linguistic Bulletin. No. 5 (41). URL: https://rulb.org/archive/5-41-2023-may/10.18454/RULB.2023.41.38 (accessed: 19.02.2025). DOI: 10.18454/RULB.2023.41.38. (In Russian)

10. *Dokumental'nyi fil'm "Soedinyayushchii miry"* [The Documentary Film "Connecting Worlds"]. thttps://smotrim.ru/video/2932072?ysclid=m7oqr2rbj2816251606. (In Russian)

# ТАТАР ТЕАТРЫ ҺӘМ КИНОСЫ ДӨНЬЯСЫНДА КАЮМ НАСЫЙРИ ОБРАЗЫ

**Гөлнара Фәндәс кызы Җамалетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Гөлүсә Габдрәшит кызы Аксой,**
Бартын университеты,
Төркия, 74110, Бартын шәһәре, Котлыбәй-Язычылар/Мәркәз,
gaksoy@bartin.edu.tr.

2025 елның 14 февралендә күренекле татар мәгърифәтчесе, тел галиме һәм язучы Каюм Насыйриның тууына 200 ел тула. «Кырык елдан артык иҗади эшчәнлеге дәверендә армый-талмый хезмәт иткән мәгърифәтче алтмыштан артык оригиналь һәм тәрҗемә ителгән әсәр һәм дәреслекләр бастырып чыгара, шул исәптән табигать белеме («Буш вакыт», 1860), ботаника һәм халык медицинасы («Гөлзар вә чәмәнзар», 1894), анатомия һәм гигиена («Мәнафигел-әгъза вә кануне сиххәт», 1894), физика һәм металл эшкәртү технологиясе («Сәнаигы гольфания», 1900), математика («Хисаплык», 1873; «Гыйльме һәндәсә» – «Геометрия», 1895), игенчелек («Гыйләме зирагать», 1892), кулинария («Иршадел-әтбиха», 1893), педагогика («Гакаид рисаләсе», 1867; «Кабуснамә», 1881; «Әхлак рисаләсе Сәгыйр», 1884; «Утыз вәгазь», «Әхлак рисаләсе Кәбир», 1890; «Тәрбия китабы», 1891), тарих («Зөбдәте мин тәварихе рус», 1890), география («Истыйляхәте җәгърафия», 1890; өч өлештән торган «Җәгърафияи-кәбир», 1898-1899), этнография («Поверья и обряды казанских татар», 1880) буенча хезмәтләр, шулай ук ел саен чыга торган егерме дүрт календарьда белемнең төрле тармаклары буенча татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдырган күпсанлы мәкаләләр урнаштыра» [1] .

Моннан 10 ел элек «Tatarica» журналында аның 9 фәнни хезмәтенә җентекле анализ ясалып, мәкалә басылып чыккан иде [2]. Әлеге мәкаләдә татар театры сәхнәсендә һәм киносында мәгърифәтче образын интерпретацияләүнең үзенчәлеген ачыклау максат итеп куелды.

Татар җәмгыяте үскән саен Каюм Насыйрины һәм аның башкарган социаль ролен кабул итү дә үзгәрә бара. Үзе исән чагында ук энциклопедист-галим Каюм Насыйрига чордашлары Казан дини училищесында һәм дини семинариядә укытканы (1855–1871), рус-татар башлангыч мәктәбен ачканы (1871–1876), рус телен белгәне, аны өйрәтү өчен көрәшкәне, рус галимнәре белән тыгыз аралашканы өчен *Урыс Каюм*, *Сатлык* кебек ямьсез кушаматлар тагалар. Физик яктан имгәнүе – бер күзенең сукыраюы – *Кылый / Сукыр Каюм* кушаматы тууга нигез була.

М. Галәү үзенең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» (1930, 1934) дигән тарихи дилогиясендә татар җәмгыятендә мәгърифәтче шәхесен кабул итүдәге каршылыкларны чагылдыра. Татарлар, бер яктан, сәүдәгәр Аитов йортында яшәүче Сукыр Каюмда укымышлы кеше – рус дөньясын яхшы белүчене таныйлар, аңа киңәш сорап мөрәҗәгать итүне урынлы күрәләр, чөнки ул русларның хөрмәтен казанган була: «Аннан соң Сукыр Каюм белән дә сүйләшеп узу зыян итмәс. Аны да урыс-улак белән аралаша дип сүйлиләр. Аит бай йортында тора бугай... Сорашырсың – күрсәтерләр. Ә инде соңыннан, кирәге булса, урысның үзенә дә барып килерсең» [3]. Икенче яктан, татар җәмгыятенең консерватив катламнары аңа руслар белән дуслыгы, җәдитчелеккә нигез булган фәнни хезмәтләре өчен ләгънәт яудыралар, шуның өчен, К.Насыйрига җәһәннәмдә урын әзерләнгән дигән фикердә торалар: «Бүтән вакытлардагы шикелле бу юлы да бүтен мәсьәләләр баягы үченче төркемне сүгүгә кайтып кала иде. Бүтен талашларның йомгагы «җәдитчеләр» дип йүртелә торган шушы төркемне мыскыллап, «җәһәннәм түбенә олактыруга» кайтып калды. Беруңайдан, татар дуньясы үчен күп кенә яңа мәсьәләләр күтәреп, үзеннән соң байтак гыйльми әсәрләр калдырып күптән түгел генә үлгән Мәрҗанине, Сукыр Каюмны, Фәезханов белән Гаспринскийны, яңа гына атагы чыга башлаган Галимҗан мулла

Барудины, урам телендә татарча әдәби китаплар язып чыгара башлаган яшьләрне – барысын бер җепкә тезеп «җәһәннәмгә аттылар» [3].

1945 елда, М. Гали Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына, күренекле татар галиме һәм мәгърифәтчесенең тууына 120 ел тулу уңаеннан, юбилярга багышланган әсәренең беренче вариантын алып килә. Әле «өлгереп бетмәгән» әсәрне ахырына җиткерергә режиссер Х. Уразиков алына. Ул авторга сюжетта Россия мөселманнарының дини башлыгы мөфти С. Г. Тәвкилевнең Казанга килүе белән бәйле вакыйгаларның кайбер якларын ачарга булыша. Соцреализм кануны нигезендә, М. Галәү дилогиясендәге кебек үк, «Каюм Насыйри» пьесасында да ике лагерьны – алдынгы фикер ияләрен һәм реакционерларны, гади халыкны һәм патша хакимиятен сурәтләүдә антитеза саклана.

Театр белгече Г. Арсланов билгеләп үткәнчә, режиссер спектакльләр иҗат иткәндә тормышчан дөреслеккә ирешергә омтыла. Рәссам М. Сутюшев Яңа Бистәдәге татар байлары йортларының интерьерларын өйрәнеп эскизлар ясый, газета һәм китаплардан алынган фотосурәтләр буенча костюмнар әзерли. Җ. Фәйзинең музыкаль увертюрасы К. Насыйри чоры рухын гына түгел, аның «бай рухи дөньясын» да ачып бирә.

Герой сәхнәгә «эффектлы түгел, ә гади, көнкүрештәгечә» килеп чыга. Режиссер, геройның белемле булуын ассызыкларга тырышып, аны китаплар кебек әһәмиятле деталь белән бизи. Герой беренче тапкыр тамашачылар алдына билгесез укучы белән чыга. Алар бергә кибеткә китаплар алып баралар. Башына бүрек, өстенә казакин, аякларына галошлы читек кигән гади бер татар карты була ул.

Х. Уразиков трактовкасында К. Насыйри – «беркемнән дә аерылмый тораган гап-гади кеше». Режиссер «образның физик кимчелеген ассызыклап, аның тышкы гәүдәләнешен дә киметеп күрсәтә». Сәхнәдә К. Насыйри образын тудыруда артистлар да үз өлешләрен кертә. Ф. Халитов башкаруында мәгърифәтче үз-үзенә чумган, хис-кичерешләрен тышкы яктан күрсәтми торган «тәбәнәк буйлы, бераз бөкрерәк, чандыр гәүдәле карт» булып пәйда була. Декламациягә көчле булган актер Н. Гайнуллин эмоциональ яктан энергияле – җәмгыятьтәге кимчелекләрне фаш итүче герой образын тудыра.

«Икенче актта режиссер Насыйри торагын бөтен нечкәлекләре белән тасвирлый»: ярымподвалдагы кечкенә бүлмә, җиһазлардан – сәке, язу өстәле, үги бала өчен тәбәнәк өстәл. Галимнең бүлмәсе китаплар һәм кульъязмалар белән тулы, тәрәзә төбен глобус бизи, стенада думбра эленеп тора. Күрше бүлмәнең ачык ишегеннән столяр верстагы һәм кораллар күренә. Режиссер уйлавынча, әлеге «әйберләр дөньясы» галимнең күпкырлы шәхес образын тудыру өчен эшләргә тиеш була. Өченче актта галим якыннары (өлкән абыйсы Габделхәй) һәм Гали Чокрый белән иркен аралаша. Дүртенче актта галим мөфтигә баш иярргә килмәгәнгә дөньяның көчлеләре геройны «хурлыклы тәртибе» өчен камчылыйлар. Спектакльнең кульминацион күренеше – геройның идея дошманнары белән очрашуы. Режиссер белә торып бу персонажларны индивидуальлектән мәхрүм итә, моның өчен аларның костюмнарын һәм ишарәләрен унификацияли. М. Галәү романындагы кебек үк, пьесада да реакционерлар мәгърифәтчене каргыйлар, шәхсән очрашканда аны туздырып ташларга вәгъдә итәләр. Тәвкилев белән очрашу кечкенә кешенең мөһим зат белән бәрелеше кебек бирелә. Мизансценада зәгыйфь, әмма көчле рухлы карт мөфтигә каршы тора. Патша генералы формасы аша, тирә-юньдәгеләргә үзенең хакимиятне гәүдәләндерүен күрсәтү өчен, мөфти өстендәге дин әһеле киемен сала. Режиссер әлеге сәхнә метафорасы аша барлыкка килгән традиция кысаларында патша хакимиятенең һәм диннең бердәмлегенә күрсәтә. К. Насыйри генерал белән аның иярченнәренә ялгызы гына каршы тора. Аңардан үкенү сүзләре көтәләр, ә герой гарәп шагыйреннән өземтәләр китерә һәм бай йортын ташлап китә. Үч итеп, галимне бүлмәсеннән куып чыгаралар һәм полиция участогына чакыралар. Әмма геройның финал монологы мәгърифәтчелек идеалы билгесе астында милләт тормышында бәхетле чор җитүен чагылдырган пәйгамбәрлек кебек яңгырый (Тулырак М. Арслановның спектакльгә анализында бирелә [4]).

Рус теленә тәрҗемә итү нәтиҗәсендә К. Насыйриның «Әбүгалисина» [5] әкият-повесте укучылар арасында популярлык казана. Биредә автор Әбүгалисина мисалында «акыл һәм әхлакый сыйфатларның байлык һәм затлылык алдында өстенлеген күрсәтергә омтыла». Татар мәгърифәтчесе «чын тарихи кешедә үзенең уңай идеалын» таба [6, Б. 187].

А. Ахунов 1975 елны татар мәгърифәтчесе мирасын «тернәкләндерү» һәм «канонизацияләү» дә мөһим вакыйга дип саный: «Аның шәхесенә һәм хезмәтләренә кызыксыну кискен артты. Насыйрины актив өйрәнә башладылар, аның әсәрләрен академик басмаларда да, балалар өчен җайлаштырып та бастыралар, тиражлары йөзләрчә мең данә белән исәпләнә. Тукай һәм Җәлил кебек шәхесләр белән бергә Насыйри исеме Советлар Союзында гына түгел, аннан читтә дә билгеле булды. Ул татар мәдәниятенең төп фигураларының берсенә әверелде, аның интеллектуаль һәм рухи мирасының символына, брендына әверелде, аның идеяләре, беркадәр җайлаштырылган һәм цензуралаштырылган булса да, яңадан актуальлеккә һәм әһәмияткә ия булдылар» [7].

Татар тамашачысы Равил Бохараевның «Каюм Насыйри урамы» пьесасы (1989) буенча эшләнгән телевизион фильмны шулай ук җылы кабул итте. Биредә данлы фикер иясе образын артист Илдус Фәиз тудырды.

1990 елда киң катлам укучылар арасында галимнең тагын бер хезмәте – «Китаб-әт-тәрбия» («Тәрбия турында китап») аеруча популярлаша, аны, цитаталарга бүлеп, бөтен дөньяга таныталар.

2019 елда К.Насыйри анализлаган татар халык мифлары мотивлары буенча, «Су анасы» дип исемләнгән Татарстанның беренче блокбастеры булдырыла. Кино-фэнтези жанрындагы бу гаилә маҗаралары фильмын режиссер Алексей Барыкин төшерә. Фильм тамашачылар тарафыннан каршылыклы бәя алды. Татар фольклорын яратучылар фильмда фольклорны бөтенләй «күрмәделәр». А. Барыкин исә фольклор мотивларын заманча технологияләр белән берләштерергә тырышып карады.

«Су анасы» нда мөселман мәдәнияте кинолентага салынган мистик көч ярдәмендә мәҗүсилек белән яраштырыла. Фильмда «балалар темасы» артында гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр, мәхәббәт һәм аралашу кытлыгы турында җитди проблемалар күтәрелә. Операторлар кадрда ерак җирләрдәге гаилә тормышын җентекләп күрсәтергә омтылалар. Картинаны сюжет линиясендә схематизм, начар эшкәртелгән диалоглар, балалар маҗарасы һәм «куркыныч» арасында баланс булмау өчен тәнкыйтьләделәр. Актерларның уйнавына, грим һәм костюмнарга карата да бик күп шелтәләр әйтелде. Барысына да Нәфисә Хәйруллинаның балаларның эш-гамәлләре белән манипуляцияләүче комсыз явыз хатынны уйнавы ошады (А. Загретдинова [9], Т. Мамаева [10] рецензиясен *кара*).

Фильмда К. Насыйри исеме татар мифларын җыючы фольклорчы буларак телгә алына. Аның бер өлеше галимнең чын әйберләре саклана торган Олы Ачасар авылында урнашкан музей интерьерында төшерелә.

Әдипнең 200 еллык юбилее алдыннан Әбүгалисина турындагы әкият-повесте Айгөл Әхмәтгалиева тарафыннан сәхнә әсәренә әйләндерелде. 2022 елның 25 мартында Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» әкият-повесте буенча куелган спектакльнең премьерасы булды (режиссеры Гөлназ Минкина). Повесть 2 пәрдәле гыйбрәтле хикәягә әверелә, ә төп вакыйгалар Мисырга күчерелә. 2023 елның 18 гыйнварында А. Әхмәтгалиева инсценировкасы нигезендә режиссер Айгөл Фәйзрахманова «Апуш» театр студиясенең яшь артистлары белән «Чулпан» мәдәни үзәге сәхнәсендә «Әбүгалисина» мюзиклын куйды (бу хакта М. Хәбетдинова мәкаләсен *кара* [11]).

2025 елда «Дөньяларны тоташтыручы» («Соединяющий Миры») документаль фильмының премьерасы булды (реж. Андрей Лысяков). «Культура» каналы заказы буенча төшерелгән картина татар мәгърифәтчесе һәм галименең портретын ясауга юнәлдерелгән. Биредә К. Насыйри үзенең фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казандагы рус һәм татар дөньясын берләштерә алган, үз чорының төрле дәрәҗәдәге белемгә ия булган кешеләрен үзара якынайтуга һәрьяклап ярдәм иткән, фәнни белемнәрен гамәлдә куллануны ачык күрсәткән һ. б. шәхес итеп тасвирлана. Фильмда К. Насыйри яшь чагында – шәкерт (Д. Зиннәтуллин) һәм җитлеккән чагында – мәгърифәтче галим (Ф. Җиһанша) буларак сурәтләнә. Төп геройның күпкырлы шәхесе картина авторының галимнәр, музей хезмәткәрләре, журналистлар, дин әһелләре белән әңгәмәсе аша ачыла. Юл хронотопы фильмда мөһим роль уйный: авыл сукмагы киң белем юлына барып тоташа. Әлеге юл – Казаның Болак елгасы белән бүленгән ике өлешен тоташтыручы юл. Игътибар төбәктәге татар халкының грамоталылык дәрәҗәсенә, патша хакимияте белән татарлар арасында арадашчы булып торучы муллалар роленә юнәлтелә. Дин әһелләре һәм татарларның белемле өлеше тарафыннан рус телен

үзләштерү процессы динамикада бирелә. Төбәк тормышы тарихи үзгәрешләр фонында яктыртыла. Чорның мәгърифәтчелек карашларына туры китереп, җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп корудa халыктан чыккан конкрет шәхеснең роле күрсәтелә. Фильм авторы галимнең, төбәк чәчәк атсын өчен, мөселман һәм православие дөньялары, реакционерлар һәм реформаторлар арасында каршылыкларны бетерү һәм диалогны җайга салу омтылышына даими игътибар юнәлтә. Фильм, эстетикасы буенча, туристлар өчен реклама ролигын хәтерләтә, чөнки ул хәзерге Казан күренешләренә, аның тирә-ягындагы табигый истәлекле урыннарга бай. Гыйлемлелек атмосферасы университет китапханәсе заллары һәм музей интерьерлары аша тудырыла. Гыйлемлелек билгеләре булып китаплар, кулъязмалар, лупа, кара белән каләм, карандаш, думбра тора. Сюжет үскән саен яшь шәкертнең сукмак аша сикерүе символик төс ала бара: К. Насыйри зур галим булып, дөньялар арасында рухи күпер салугаирешә. Мәгърифәтче шәхесенең төрле яклары хәзерге татарларның төрле катлам вәкилләре тарафыннан ачыла. Фильмда, документаль чыганаклар ярдәмендә, галимнең дәрвишлеге турындагы мифлар җимерелә. Кызганычка каршы, герой үзе «телсез» килеп чыккан. Фильмда аның хезмәтләре цитаталанмый, фәнни казанышлары конкретлаштырылмый. Фильмның зур өлеше рус теленең аңа зур белем дөньясына юл ачуына багышлана [10].

Энҗе Дусаева һәм Динә Хәбибуллина «Каюм Насыри: мехом наружу» спектакль-променадын (сценарий авторы М. Гафурова) иҗат иттеләр. Сәфәр маршруты Казанның Печән базары, Киров бакчасы, Карл Фукс йорты, китап кибете, Галиев мәчете, Каюм Насыйри музей-йорты аша уза. Спектакль галим турында истәлекләрнең ничек саклануын күрсәтүгә юнәлдерелгән. Экскурсия вакытында төркем каршысына Каюм Насыйриның (Илгизәр Хәсәнов) туганнан туган сеңлесе Гөлхәбирә Насыйрия (Динә Хәбибуллина) килеп чыга. Заманында галим аны «Фарсыча-гарәпчә-төркичә (татар) сүзлеге»н төзергә рухландырган. Ул галимнең фәнни эшчәнлеге турында сөйли. Экскурсантлар ике шәкертнең сөйләшүен тыңлыйлар, алар К. Насыйрины семинариядә укытканы өчен гаеплиләр. Китап кибетендәге кешеләргә К. Насыйри календарьлар чыгара башлавы турында сөйли. Экскурсия музей-йортта тәмамлана, анда килүчеләрне галимнең тормыш рәвеше белән таныштыралар. Финалда К. Насыйриның васыяте яңгырый, ул аның фәкыйрьлеге, атеизмы турындагы мифларны җимерә.

К. Насыйри хезмәтләре бүгенге көнгә кадәр актуальлеген югалтмады. Аларны таныту өчен даими эш алып барыла. 2024 елның ноябрендә Минск шәһәрендә Белоруссия дәүләт технология университеты базасында Казан федераль униврситеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Каюм Насыйри үзәге ачылды, ул – исәп буенча инде 15 нче үзәк. Мондый үзәкләр Астана, Баку, Бишкек, Ташкент кебек чит ил шәһәрләрендә һәм Россиянең 10 төбәгендә эшли.

Галим-этнографның 200 еллыгына багышлап, РФ Үзәк банкы 2 сум номиналлы истәлекле көмеш тәңкә чыгарды.

Якын киләчәктә К. Насыйриның «Байдек» әкияте буенча төшерелгән яңа нәфис фильм чыгар дип көтелә. ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2024 елда режиссер Ф. Мәхмүдовка («Махаббат» студиясе) 2 млн. сум күләмендә субсидия бүлеп бирелде. Гаилә кыйммәтләрен танытучы бу фильм «Байдек маҗаралары» дип атала.

Әлбәттә, кино һәм телевидение К. Насыйрины медиа, танылган шәхескә әверелдерүдә һәм галимнең мирасын танытуда мөһим роль уйный. Татар язучысының төрле жанрдагы фильмнар героена әверелүе дә сөендерә. Иҗат итүчеләрнең теге яки бу жанр эстетикасы нигезендә биографик дөреслеккә, мәгърифәтче галимне үз хыял-теләкләре булган тере кеше итеп күрсәтергә омтылулары да зур игътибарга лаек.

**Әдәбият**


1. Каюм Насыйри // Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркологическая лингвистическая школа/ сост. М. З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 32–36.
2. *Галиуллина Г. Р., Юсупова А. Ш.* Каюм Насыйри хезмәтләрендә татар белеме нигезләре (галимнең тууына 190 ел тулу уңаеннан) // Tatarica. 2015. №4. С.7–17.
3. *Галяу М.* Мөһаҗирләр. Казан: Татар. кит. нәшр. // URL: kitaphane.tatarstan.ru›eng/file/pub/pub_26769.doc 6lr%3D43%26mime%3Drtf%26l10n%3Dru%26sign%3De07235d8566f37fb9f984de60d796c72%26keyno%3D0%26nosw%3D1 (дата обращения 14.02.2025)
4. *Арсланов М.* Спектакль «Каюм Насыри» на сцене Татарского академического театра им. Г. Ка-

мала // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2013. №3–4. С. 248–255.

5. Насыри К. Абугалисина / Пер. с тат. Б. Ибрагимов; [Обработка Г. Лутфи]. – Казань: Таткнигоиздат, Ред. юнош. дет. лит., 1957. 60 с.

6. *Гайнуллин М.* Татарская литература XIX в. Казань: Тат. кн. изд-во, 1975. 307 с.

7. *Ахунов А.* Юбилей для галочки: Татарстан не заметил 200-летие великого просветителя // Бизнес-Онлайн. 16 февраля 2025 г. // URL: https://www.business-gazeta.ru/article/663317

8. Насыри К. Китаб-эт-тэрбия. Книга о воспитании. Казань, Татарское книжное издательство, 1992.144 с.

9. *Хабутдинова М. М.* Образ Абугалисины в татарской литературе // Russian Linguistic Bulletin. 2023. №5 (41). URL: https://rulb.org/archive/5-41-2023-may/10.18454/RULB.2023.41.38 (дата обращения: 19.02.2025). — DOI: 10.18454/RULB.2023.41.38

10. Документальный фильм «Соединяющий миры». thttps://smotrim.ru/video/2932072?ysclid=m7oqr2rbj2816251606